РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРЛАТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

31 гыйнвар 2024 ел

№ 1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Норлат авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2024 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 23 гыйнварындагы 46 номерлы карары, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Норлат авыл җирлеге башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 1 февраленнән Буа муниципаль районының Норлат авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 8370,20 суммасында 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Норлат авыл җирлеге башкарма комитетының 2023 елның 23 гыйнварындагы 3 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Норлат авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» карарын үз көчен 2024 елның 1 февраленнән югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар имзаланган көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районының Норлат
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе М.Х. Закиров

Буа  муниципаль районы
Норлат авыл җирлеге
башкарма комитетының
31.01.2024 елның № 1 карарына
1 кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Норлат авыл җирлегендә
01.02.2024 елдан җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле
БӘЯЛӘРЕ

| № т/б | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. | Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү. | 5929,45 |
| 3. | Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару | 841,20 |
| 4. | Күмү (кабер казу һәм күмү) | 1599,55 |
| Барлыгы | | 8370,20 |

Буа муниципаль районы
Норлат авыл җирлеге
башкарма комитетының
31.01.2024 елның № 1 карарына
2 кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Норлат авыл җирлегендә
01.02.2024 елдан җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле
БӘЯЛӘРЕ

| № т/б | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. | Җәсәдләү | 2963,06 |
| 3. | Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү. | 2963,06 |
| 4. | Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару | 836,22 |
| 5. | Күмү (кабер казу һәм күмү ) | 1607,86 |
| Барлыгы | | 8370,20 |